Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8-9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 86

1. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз. Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 3 балл.

1.1. Дәүләт турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Дәүләтне төзү – ул икътисади һәм социаль җәмгыятьнең үсеш нәтиҗәсе.

Б. Дәүләтнең иң мөһим билгеләренең берсе – ул суверенитет.

а) дөрес А

б) дөрес Б

в) ике фикер дә дөрес

г) ике фикер дә дөрес түгел

1.2. 2026 елда Татарстанда М.Ш.Шаймиевны беренче президент итеп сайлауга ничә ел була?

а) 25

б) 30

в) 35

г) 20

1.3. Сәнгать әсәренең авторлыгы турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Сәнгать әсәренең авторы 21 яшькә җиткән кеше генә була ала.

Б. Әсәрнең авторы яшкә карамыйча һәркем була ала.

а) дөрес А

б) дөрес Б

в) ике фикер дә дөрес

г) ике фикер дә дөрес түгел

2. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап 1 балл. Барлыгы 7 балл.

2.1. Җәмгыятьнең өч үсеш баскычын күрсәтегез:

Җавап: _____

2.2. Гомуми белем бирүнең дүрт баскычын күрсәтегез:

Җавап:_____

_____

3. Танылган кешеләрнең фикерләрен укыгыз. Китерелгән ике фикер дә бер җәмгыять төшенчәсенә багышланган. Әлеге төшенчәне билгеләгез. Дөрес җавап өчен 3 балл.

Соңыннан яхшы кол булыр өчен, башта начар *** булырга кирәк. (Шарль Монтескье).

*** үз дәүләте өстеннән хакимлек итәргә тиеш (Аристотель)

Җавап: _____

4. Төрле илләрдә закон чыгаручы хакимиятенең (парламентның) үз исемнәре бар. Парламент исемнәре һәм аңа туры килүче ил арасында тәңгәллекне билгеләгез. Сул баганадагы һәр хәрефкә уң баганадан тиешле санны сайлап алыгыз. Илләр саны күбрәк булуына игътибар итегез. Дөрес тәңгәллек өчен 1 балл. Барлыгы 10 балл.

Илнең парламент исеме	Ил
А) Мәҗлес	1) Швеция
Б) Хурал	2) ФРГ
В) Корылтай	3) Әзербайҗан
Г) Бундестаг	4) Татарстан
Д) Дәүләт Советы	5) Бразилия
Е) Альтинг	6) АКШ
Ж) Ил Түмән	7) Саха (Якутия) Республикасы
З) Ригстаг	8) Башкортостан
И) Конгресс	9) Исландия
К) Кортес	10) Бөекбритания
	11) Монголия
	12) Австралия
	13) Испания

Җавап:

А	Б	В	Г	Д	Е	Ж	З	И	К

5. Аристотель дәүләт төзелешенең 6 формасын тасвирлаган:

А – тирания, Б – монархия, В – аристократия, Г – олигархия, Д – демократия, Е – полития

Аларның кайсысын ул дөрес, кайсысын дөрес булмаган дип саный? Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 6 балл.

Җавап:

Дөрес	Дөрес булмаган

6. Мәсьәләнең шартын игътибар белән укыгыз һәм сорауга җавап бирегез. 2 балл.

16 яшьлек Ленар хезмәт килешүе төзи. Ленар эшкә урнашкан фирма директоры, аңа барлык хезмәткәрләр кебек үк 9.00 дан 18.00 сәгатькә кадәр (1 сәгать төшке аш), дүшәмбедән җомгага эшләргә кирәклеген хәбәр итә. Ленар фикеренчә, 18 яшь тулмау сәбәпле ул башкаларга караганда азрак эшләргә тиеш. Ленарның юридик факультетының беренче курсында укучы сеңлесе, балигъ булмаган баланың эш вакыты атнага 28 сәгатьтән артмаска тиеш дип әйтә. **Ленарның сеңлесе бу очракта дөрес аңлатма бирдеме?**

А - Юк, чөнки 16 яшьтән өлкәнрәк кешеләр өчен эш вакытының гомуми озынлыгы балигъ булганнар кебек үк. 16 яшькә кадәрге кешеләр өчен генә кыскартылган эш вакыты билгеләнгән.

Б - Юк, чөнки балигъ булмаганнар өчен эш вакыты атнага 5 сәгать тәшкил итә.

В - Юк, чөнки балигъ булмаганнар өчен эш вакыты атнага 35 сәгать тәшкил итә.

Г - Юк, чөнки балигъ булмаганнарның 18 яшькә (балигъ булганчы) кадәр хезмәт килешүе буенча эшләргә хокуксыз.

Җавап: _____

7. Икътисади мәсьәләне чишегез. Дөрес җавап өчен 5 балл.

Динар, яхшы башкарылган эш өчен 300 000 сум премия ала. Аны арттыру теләге белән ул премияне елына 15% белән ике елга ашыгыч депозитка сала. Ике ел узгач, Динар барлык акчаны счеттан алып, 90:1 (1 евро өчен 90 сум) курсы буенча еврога алыштырды. Билгеле бер вакыттан соң Ленар туристик сәяхәт өчен евро белән рубльне алыштырырга тиеш була. Ул банкка мөрәҗәгать итә һәм мәгълүмат ала:

евро сатып алу - 90,50 сум. Евро сату - 92,50 сум. **Рубль өчен евро алмашу операциясеннән соң Динар күпме сум алды?**

Җавап: _____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

8. Татарстан Республикасы конституциясеннән өзекләрне укыгыз һәм буш (сан белән күрсәтелгән) урыннарны тутырыгыз. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 20 балл.

Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе составындагы (1_____) хокукый дәүләт.

Татарстан Республикасында хакимият аның (2 _____) тарафыннан турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында дәүләт телләре – тигез хокуклы (3 _____) һәм (4 _____) телләре.

Халык хакимиятенең иң югары турыдан-туры чагылышы – (5_____) һәм ирекле сайлаулар.

Дини берләшмәләр дәүләттән (6 _____) һәм закон каршында тигез.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы – Татарстан Республикасы парламенты – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең даими эшләүче вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару органы. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (7 _____) елга сайлана.

Татарстан Республикасы (8 _____) дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була. Закон нигезендә пассив сайлау хокукына ия булган һәм 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы сайланырга мөмкин.

Татарстан Республикасында хөкем итү бары тик (9 _____) тарафыннан гына гамәлгә ашырыла

Татарстан Республикасының (10_____), Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны – Татарстан Республикасы дәүләтчелеген, Татарстанның күпмилләтле халкы үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдыручы рәсми символлары бар.

Җавап:

1.	
2.	
3.	
4.	
5.	
6.	
7.	
8.	
9.	
10.	

9. Дәүләт институтлары һәм ул урындагы кешеләрнең функцияләрен мисаллар китереп язып чыгыгыз. Дөрес җавап өчен 3 балл. Барлыгы 9 балл.

1) РФ Президенты

_____

_____

_____

2) Федерация Советы

_____

_____

_____

3) РФ Дәүләт Думасы

_____

_____

_____

10. Росстат (Федераль дәүләт статистикасы хезмәте) мәгълүматлары нигезендә төзелгән таблица мәгълүматларын анализлагыз. Максимум 10 балл.

11 ел эчендә Россия Федерациясе төбәкләренең даими халык саны.

РФ регионнары	2025 елгы халык саны	2020 елгы халык саны	2016 елгы халык саны
Адыгей республикасы	500731	463167	451480
Татарстан республикасы	4019606	3902888	3868730
Иркутск өлкәсе	2322292	2391193	2412800
Ленинград өлкәсе	2059479	1875872	1778857
Свердловск өлкәсе	4221452	4310681	4330006
Севастополь шәһәре	558302	449138	416263

Алынган мәгълүматлар нигезендә нинди нәтиҗәләр ясарга мөмкин?

Җавап: _____

_____

_____

_____

_____

_____

_____

11. Россиянең күренекле галимнәре һәм аларның ачышлары арасындагы тәңгәллекне билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 7 балл.

1. Александр Бутлеров
2. Сергей Боткин
3. Николай Лабочевский
4. Гыйлем Камай
5. Ренат Акчурин
6. Петр Капица
7. Леонид Канторович

А - Органик матдәләрнең химик төзелеше теориясен булдыра. Казан университетын тәмамлаган. Санкт-Петербург университетында укыткан.

Б - Математик, сызыклы программалауны булдыручыларның берсе. 1975 елда Нобель премиясенә лаек була.

В - Организм турында тәгълимат булдыра. Беренче тапкыр А. вируслы гепатитны тасвирлый.

Г - Евклидча булмаган геометриясен төзүче.

Д – Химия фәннәре докторы. Мышьяк-органик кушылмалар химиясе буенча фәнни юнәлешкә нигез салучы.

Е – Кардиохирург. 1996 елда Б.Н.Ельцинның йөрәгенә операция уздыра.

Ж – Нобель премиясе иясе (1978). Газ сыекландыру өчен сәнәгать җайланмасын уйлап табучы. Мәскәү физика-техник институтына нигез салучыларның берсе.

Җавап:

1.	2.	3.	4.	5.	6.	7.

12. Сезнең алдыгызда сурәт. 4 балл.

Сурәткә кагылышлы дөрес җавапларны күрсәтегез:

А) Рәсем Россия Федерациясе гражданнарының иң мөһим конституцион бурычларының берсен тормышка ашыруны күрсәтә.

Б) Хәрби хезмәт - Россия Федерациясенең барлык гражданнары өчен бурыч һәм мактаулы хокук.

В) Хәрби хезмәткәр - бер үк вакытта социаль статус та, социаль роль дә.

Г) Россия Федерациясендә хәрби хезмәтне ил гражданнары гына түгел (чакыру буенча), ә гражданлыгы булмаган кешеләр дә (ирекле рәвештә) уза.

Д) Россия Федерациясендә барлыкка килгән хәрби хезмәтне гуманизацияләү тенденциясе хезмәт итәргә теләмәгән очракта аны үтәүдән азат ителү мөмкинлегеннән гыйбарәт.

Е) Хәрби хезмәт тәртип, җаваплылык һәм башкалар кебек шәхси сыйфатларны үстерә, кешенең физик үсешенә ярдәм итә.

Җавап: _____